| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |
| КАРАР | ПОСТАНОВЛЕНИЕ |
| № 183 | 24.12.2015 ел |

**«Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген һәм торак урыннарны алу турында»**

Күпфатирлы йортта авария хәлендә дип танылган һәм җимерелергә тиешле торак урыннар милекчеләре булмаганга, аларны билгеләнгән вакытка сүтү, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 10 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 56.3, 56.6 статьясы, «Күпфатирлы торак йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турында» 2009 елның 11 декабрендәге 28 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 16:37:010604:23, гомуми мәйданы 2435.52 кв.м. булган, Татарстан Республикасы Спас районының Болгар шәһәрендә Нагаев урамы буенча 63 нче күпфатирлы торак йорт биләгән, авария хәлендә дип танылган һәм җимерелергә тиешле җир участогын муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алырга.

2. Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеге алу сәбәпле, муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алу юлы белән Спас районы, Болгар шәһәре, Нагаев урамы, 63 нче йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йорт милекчеләреннән Закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тартып алынды.

3. Әлеге карар басылып чykканнан соң ун көн дәвамында, күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Спас бүлегенә җибәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//htth:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм «Яңа тормыш» район газетасында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

РТ Спас муниципаль районының
Болгар шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Тюленев

ТР Спас муниципаль районы
Болгар шәһәр Башкарма комитетының
2016 елның __ _______ ___ номерлы карарына
кушымта.

Болгар шәһәрендә Нагаев урамы буенча 63 нче йорттагы торак урыннар исемлеге, алар муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алу юлы белән алынырга тиеш.

| № | Торак урыны номеры | Торак бинаның кадастр номеры | Гомуми мәйдан (кв. м) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 16:37:010604:198 | 48.9 |